ЧАЯН



ISSN 0136-7110

САТИРА
ҺӘМ ЮМОР
ЖУРНАЛЫ
THE MAGAZINE
OF SATIRE
AND HUMOUR

СКОРПИОН * SCORPION ГЫЙНВАР * 2012 * КАЗАН

2

Александр ШУЛЬПИНОВ



АННАН-МОННАН
ИНФОРМ
СОҢГЫ ХӘБӘ!РЛӘР

Җинаятьчеләргә билгеләнгән җәзаларны йомшарту йөзеннән, гомерлек төрмәне ипотека белән алыштыру тәкъдим ителә.

«Бердәм Россия» әгъзасы яңа туган улын Владимир Владимирович дип атаган.

Президент килүенә шифаханәгә сәламәт авырулар китергәннәр.

Кытайда паспортларны фотографиясез генә бирә башлаячаклар.

Киевның Т. Бульба исемендәге аэропортында республикабыз делегациясен хәләл сало һәм хәләл горилка белән каршы алдылар.

Математик Е. Хәчтерүшанскийга коммуналь счет-фактуралардагы саннарның очына чыккан өчен Лобачевский премиясе бирелде.

Дөньяда иң яхшы «ялган детекторы» үтүк заводында эшләнде.

Финанс университетында ришвәт алу факультеты ачылды.

Михаил Ходорковский узган елның иң яхшы тылсымчысы дип табылган. Ул, үткәннәргә кайтып, анда яңа икътисадый җинаятьләр кылып йөри.

Полиция бер төркем ялган дипломнар ясаучы жуликларны тоткарлады. Операция белән экономик фәннәр докторы лейтенант Хәбибуллин җитәкчелек итте.

Математика укытучысы хезмәт дисциплинасын бозган өчен хезмәт дәресләре укытучысы итеп күчерелгән.

Безнең ЮХИДИ инспекторлары иң итагатьлеләр дип табылган. Алар машинаны туктату белән, беренче чиратта: «Үзегезне ничек хис итәсез?» — дип сорыйлар икән.

Зират директоры үзен эш урынында җирләргә дигән васыять калдырган.

ӘЙТСӘЛӘР ӘЙТӘЛӘР

АКШның авыл хуҗалыгы министры белән сөйләшкәндә, мин аңа турыдан-туры сорау бирдем. Сез Бөтендөнья сәүдә оешмасы члены, һәм аның кагыйдәләре буенча үз предприятиеләрегезгә ярдәм күрсәтергә тиеш түгелсез... Беләсезме, ул нәрсә диде? «Төкерәбез һәм төкерәчәкбез без ул кагыйдәләргә: авыл хуҗалыгы — безнең стратегик зона ул», — диде...



Айрат ХӘЙРУЛЛИН,
Дәүләт Думасы депутаты

МУНЧА

Тукталышта бер танышымны очраттым. Торган булабыз шулай янәшә. Автобусы да килми, каһәр!

– Кая барыш, – дигән булам, әтәчегез күкәй саламы, дигән сыманрак, битараф кына. Беләм бит инде, бу йолкыш, барса да, шул оптовый базага барыр инде. Бер айга җитәрлек продукция төяп кайтырга. Анысы да абыйсыннан алып торган социаль проездной белән.

– Коттеджга, мунча кирәргә: – димәсенме бу.

Битарафлыгымны юып алдылармыни! Карасам, чынлап та, олы гына сумкасыннан кипкән каен яфраклары тырпаешып тора моның!

– Кит аннан! – дим. – Нинди коттедж?! Әллә берәр бай туганың теге... Ну... Мирас алдыңмыни?

– Ю-ук, – ди. – Каян килсен миңа андый туган!

– Алайса, банк баскансыңдыр әле?

– Юк ла, – ди. Үзе серле генә елмая.

– Соң, күрешмәгән арада түрә булмагансыңдыр ич? – дим соңгы өмет белән.

– Юк инде. Син тар фикер йөртәсең, – дигән була. – Мин, хәзерге тел белән әйткәндә, долгосрочное вложение ясадым. Менә уйлап кара: безнең "ЧэПэ" нәчәлнигы, бу коттеджын төзегәндә, ай саен минем зарплатамны "печеп" барды. Өч елга байтак җыелгандыр бит, әй, туган? Менә хуҗадан үземнең өлешне мунчалата сорап карыйм әле, ятып калганчы атып кал, – дип әйтте дә, килеп туктаган автобуска утырып китеп тә барды...

Мин авызымны ачып карап калдым. Вәт кыюлык кешедә! Эшеннән очып чыкмаса, хәзер гомер буе атнасына кимендә бер тапкыр нәчәлник кабинетында рәхәтләнеп "мунча керәчәк" бит бу!

Гүзәл МӘРДАНОВА

ЧАЛЛЫ



Валерий ТАРАСЕНКО (Мурманск)

Александр КОХАН (Киев)



Авыздан чыпчык

Исерек кыяфәтеннән башка аның үзе белән бернәрсә дә юк иде.

Ун тартма ялган аракы, аның ялганлыгы тулысынча ачыклангач, складка җибәрелде.

(протоколлардан)

Беренче баламны мин икенче ирем белән яшәгәндә, ләкин беренче иремнән таптым.

(гаризадан)

Авыл клубы һәрвакыт бикле, телевизордан карар әйбер юк, һәм шуңа күрә самогон куып, сугышып ял итәргә туры килә.

Башта мин секретаршага укырмын дигән идем, аннан соң уемнан кире кайттым. Куркыныч профессия: йә начальникның хатыны чәчеңне йолкый, йә сөяркәсе күз төбенә бирә.

Хатыным үзенә игътибар җитмәгәнгә зарлана. Мин үзем эштән соң бокс белән шөгыльләнәм, ә аңа, ничектер, кулым җитми.

(хатлардан)

Колбасада мыек формасындагы таракан фрагментлары табылды.

Контроль үлчәү вакытында 100 граммлы пакетның авырлыгы 85 грамм булып чыкты. Ә ул 90 грамм булырга тиеш.

(актлардан)

Үле ир-ат гәүдәсе җинаятьченең исемен пышылдарга өлгерде, ә аннан соң бөтенләй үлде.

(рапорттан)

Рафинад ЗАҺРИБУЛЛИН җыйды



Хөрмәтле Чаян! Озак еллар буе ир-атларны эчкечелеккә өйрәтү үз эшен эшләде, ахры. Ирләребез күзгә күренеп үзгәрде. Бөтенесендә — сыра эчкәннән зур корсак...

Р. БОРҺАНОВА

ТҮБӘН КАМА

— Элек ул зур корсаклар сырадан була иде, — диде Шомбай ага, хатны укып чыккач. **— Хәзер киресенчә: зур корсаклар — сыра өчен...**

Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ

ДӨНЬЯ ҮЗЕ ЧЫНЫКТЫРА

Күлмәк кидем — каралды,
Күмхуҗ кордым — таралды.
Үткәннәре үткән инде,
Алдагысы караңгы.
Нигә сүнде яктылык,
Кемнән көтик яхшылык?
Кызык түгел, килер көнгә
Яшәмәгәч ясканып.
Хаклар үрли түрләргә,
Сәмән җитми түләргә.
Кем куана, тере килеш
Төртеп безне гүрләргә.
Әй, ямансу күзләрдә,
Тоз шыгырдый тезләрдә.
Тырышмагыз... Өмет — исән!
Без күнеккән түзәргә...



Тәнзилә ДАВЫДОВА



Ул бит кинода гына бөтенесе дә тиз һәм шома бара. Атаклы комедиядәге кебек — «Подскользнулся, упал. Очнулся — гипс».

«Эх, минем дә шулай гына буласы иде!» — дип уйлап куйдым мин, өемә кайтып җиттем дигәндә аягымны сындыргач. Гипс салыр өчен тизрәк шифаханәгә барырга кирәк иде, ә өйдән чакырган «Ашыгыч ярдәм» машинасы дүрт сәгатьтән соң гына килеп җитте.

Кул-аягын сындырган бичаралар арткаaннан-арта торды, чөнки Яңа ел алдыннан Казан урамнары тоташ шугалакка әверелгән иде.

Бәйрәмнәрдән соң гипска сорау арта барды. Бер танышым аягын каерган булып чыкты. Адоратский урамы, 32 нче йортта урнашкан травмпунктка шылтыраткан һәм чиратта утырмас өчен кабул итү вакытын ачыкларга тырышкан. Аңа бу вакытның иртәгә генә җитәчәге турында хәбәр салганнар. Иртәрәк ярдәм алу мөмкин түгел — аның ишеләр болай да буа буарлык икән.

Бозлы урамнар темасы Удмуртиядә яшәүче инвалид Гуля Хәмитованың хатында да чагылыш тапкан. Казаннан өенә ул 8 гыйнвар көнне кайтырга булган. Машина тимер юл вокзалы бинасының ишегенә кадәр барып җитә алмаган — аркылы куелган машиналар һәм төзелеш җайланмалары комачаулаган. Таягына таянып, Гуля вокзал ишегенә таба юл тоткан. Кая, ди, ул! Вокзал алдындагы мәйдан, әлеге дә баягы, шугалак диярсең!

Гуля перронга шәһәр яңы вокзалы аркылы үтәргә уйлый, ләкин юлны кырыс контролерлар һәм тимер турникетлар томалап тора. Анда үтәр өчен еракка баручы поездга түгел, ә электричкага



билеты алырга кирәк!

Контролерларның йөрәген эретер өчен инвалид хатынга үзенең нинди хәлдә калганын аңлатып, ярыйсы гына көч түгәргә туры килә.

Гуля белән чагыштырганда студент Михаил Струков бөтенләй өметсез хәлдә кала. Ул иртән Арчага апасының туган көненә барырга җыена. Өеннән чыгып, йөзләп адым үтү белән, таеп китеп башы белән тротуарга барып төшә. Туган көн турындагы матур уйлар, әлбәттә, челпәрәмә килә. Маңгаендагы зәңгәр түмгәккә боз кисәге куеп, акрын гына туган йорт ягына юл тота егет.

Гражданнарның куркынычсызлыгы өчен Казан хакимиятендә административ-хуҗалык инспекциясе булдырылган. Шәһәр 44 секторга бүленгән, ә аларны карау өчен 44 дозорный билгеләнгән. Аларның вазыйфасы — урамнарда тайгак урыннарны ачыклап, гаеплеләргә штраф салу. Ләкин бу чара әллә ни файда бирми, ахры. Яңа елның ун көне эчендә генә ике мең чамасы кеше имгәнә.

Рәсми отчетлар буенча, көрәк һәм лом белән коралланып, боз һәм кар белән көрәшергә 1852 урам җыештыручы чыга. Ләкин бу көрәштә боз белән кар җиңә шикелле. Урам җыештыручылар үзләренең эш урыннары өчен бик өзелеп китми, күрәсең — айлык 10 мең сум акча табигать күренешләре белән көрәшергә зур батырлык кыларга этәргеч була алмый.

Шунысы кызыклы, казанлылар йорт тирәләрен чистарткан өчен ай саен 54 (!) миллион сум түләп бара. Бу сумманы көрәк батырларының санына бүлсәң, бөтенләй башка нәтиҗә чыга. Хәер, ул акчаның нинди «мерседес»ларга әверелгәнен барысы да аңлый.

Һәр адымыңны үлчәп, ком да сибелмәгән бозлы тротуардан атлаганда, үзеннән-үзе бер иске мәзәк искә төшә:

— Сахара чүлендә социализм төзесәләр ни була?

— Ком дефицитка әверелә.

Күргәнебезчә, социализм килә дә китә, ә ком проблемасы һаман кала бирә.

Шәүкәт ГӘРӘЙ

КАЗАН

Елена ХИТРОВА



— Бу шайтан алгыры дворник тагын юлга ком сипмәгән!

— Авызыңны үлчәп ач — мин ул дворник!

Эрнест ДЫШАЕВ



— Управляющийның башына боз кисәге төшүе булды, шунда ук түбә чистартырга керештеләр!



ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

ЧАБАРГА КИРӘК...

— Талоннар белән чиратсыз керегез. Нәрсәгә зарланасыз?

— Доктор, мин бернинди сәбәпсез әллә нинди күңелсезлекләр кетәм.

— Эч йомшарта торган дару эчегез.

— Нигә?

— Күңелсезлекләр котәргә конкрет сәбәп булыр. Ә сездә нәрсә?

— Ютәлем бетми.

— Сулагыз! Суламагыз! Сулагыз! Суламагыз! Суламагыз! Әй җанкисәгем, сезгә реанимациягә ятарга кирәк! Давай, кем анда тагын!

— Улым, сидек бөтенләй чыкмый.

— Сезгә ничә яшь?

— Сиксән.

— Ызначит, чыгып беткән, бабакай. Кем бар тагын?

— Доктор, минем йөзем зәпзәңгәр!

— Күрәм, дальтоник түгел. Сезгә срочный ампутация кирәк. Хирургка чабыгыз! Ә сездә нәрсә?

— Тамак авырта, температура...

— Җылырак киенергә кирәк. Барыгыз. Ә минем тунны калдырыгыз! Кем анда, керегез!

— Минем никтер эчем авырта.

— Хәзер карарбыз. Пульс тәртиптә. Әйбәт йоклыйсыз. Аппетитыгыз шәп. Менә сезгә рецепт — пульс, йокы, аппетитның эзе дә калмас. Э сезгә ни булды?

— Ярдәм итегез, доктор, хәлем бик начар... Ниндидер гөмбәләр ашаган идем.

— Нинди?

— Белмим, карап җиткермәдем.

— Срочно күз врачына... Әйе, керегез!

— Доктор, минем кулым авырта!

— Болай авыртамы?

— Авырта!

— Ә болай?

— Авыртмый!

— Менә шулай йөрегез! Тагын кеше бармы? Юк. Шәп, миңа икенче эшкә — дежурствога чабарга кирәк...

Наил ТАБИБОВ

АВЫРУ ТАРИХЛАРЫННАН

Авыру үзенең хәле турында берни дә әйтә алмый. Клизма ясап карадык, барыбер сөйләшми.

Күзләренә зарлана: хәләл җефетен күрше хатынынннан аера алмый.

Авыру үзен начар тотты, шуның өчен аңа тагын бер операция ясалды.

Пациентның иртәнге ашка — ботка, әбәткә диарея булды.

Реанимация чаралары файда бирмәде — ул үзе аңына килде.

Тотып карагач, китерелгән авыруның кыз булуы ачыкланды.

Көчле махмырга һәм йөрәге януга зарланып мөрәҗәгать итте.

К. травмпунктка күпсанлы туганнары белән бергә китерелде.

Авыруның хәле яхшыруы күзәтелә — ул үзе аякларын суза.









Табибларның, протест акциясенә чыгып, ни теләгәннәренә хакимияттәгеләр һич төшенә алмаган. Чөнки аларның транспарантларындагы язуларын укый алучы юк.

• • •

Атаклы Пирамидаларны коллар түгел, ә шимбә өмәләренә йөрүчеләр төзегән, имеш.

• • •

— Улыңны әйтәм, күзгә күренеп үсә, колакларыннан тартасың, ахры?

— Юк, ай саен мониторны гына 5 сантиметрга күтәреп куям.

• • •

Бер егетне йөргән кызы ташлый. Шуңа борчыла егет. Аны әтисе тынычландырырга тырыша:

— Шуның өчен хафаланаламмыни? Иртәгә башкасын табарсың!

— Шул-шул, менә — иртәгә, ә бүген мин нишләргә тиеш соң?!

• • •

— Апа, ә Вәлине чыгарырлармы икән?

— Әлбәттә. Менә әйткән иде диярсең, 10 елын тутыруга чыгарырлар да җибәрерләр.

• • •

— Доктор, менә минем анализларым... Минем бик яшисем килә, әлбәттә.

— Моның өчен анализлар гына җитми шул. Ә акчагыз бармы соң?

• • •

— Сиңа ябыгу бик килешә. Диета буенча туклануның файдасыдыр инде?

— Әйе, кишер, чөгендер һәм бәрәңге.

— Пешердеңме, әллә кыздырдыңмы?

— Казыдым!

• • •

— Хәлим, нигә син дәфтәреңә әтиебезнең фотосурәтен ябыштырдың?

— Ә миңа укытучым: "Сиңа өй эшен эшләргә булышкан, әмма бер мәсьәләне дә дөрес чишә алмаган җүләрне күрәсем килә", дигән иде.

• • •

— Сезнең дисконт картагыз бармы?

— Мин начәлнигыма сатып алам. Аның акчасы жәл түгел.

• • •

Янып бетә язган бина янында бите-башы корымга буялган, һәм киеме утта кызып, бераз күмерләнгән ир кешене репортерлар уратып алган.

— Сез янгын вакытында шушы авыр сейфны, стенадан кубарып алып, ничек бинадан урамга сөйрәп чыгара алдыгыз?

— Минем урында булса һәр кеше шулай итәр иде. Мин бу офиста эшлим, ә иртәгә получка...

Мәзәкләрне җибәрделәр: Г. ГРОВЕР (Тымовск, Сахалин), **В. ПОСТНОВ** (Шарипово, Красноярск өлкәсе), **А. ВӘРИСОВА** (Владикавказ), **Р. ГАЛӘВИН** (Шәмәрдән, Татарстан), **А. ПУЧКОВ** (Кузнецк), **М. ФӘЛӘХОВ** (Казан).

Бәйләмне Рәшит ЗӘКИЕВ әзерләде.

Анатолий ВАСИЛЕНКО (Киев)



ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН СЫНАМЫШЛАРЫ

Иртәнге сәгатьтән үк урам тутырып исерекләр һәм этләр йөрсә, димәк, кичә бәйрәм булган.

Начальнигың белән телгә килсәң, көт тә тор — хезмәт хакың азаячак!

Әгәр ир хатынын ишеген ачып машинага утырта икән, йә машинасы яңа, йә — хатыны.

Көне буе кар яуса, икенче көнне эшкә соңга калачаксың.

Берәрсе артыңнан сүгенеп кала икән, димәк, син бүген йөзгә чибәр, күңелгә көр күренәсең.

Автобуста барганда берәр яшүсмер торып урын бирсә, димәк, аның чыгар вакыты җиткән.

Кинәт кенә бер бик якын дустың исеңә төшсә, димәк, синең акчаң беткән.

Берәрсе хатынын мактый башлаган икән, димәк, аны сөяркәсе ташлаган.

Казан урамында итәк кигән хатын-кыз күрәсең икән, белеп тор — ул, беренчедән, хатын-кыз түгел, ә озын чәчле егеткәй булыр, икенчедән, ул итәк кимәгән, итәк дигәне елның бер фасылында да алышынмый торган җилән булыр.

Шәһәрдә "бөке"ләр күбәйсә — ике елдан Универсиада булачак.

Бай кешенең кулында конверт күрсәгез, ул йә ришвәт алган, йә судка повестка тоткан.

Әгәр пенсия 15 процентка арта икән, көт тә тор — икенче көнне үк азык-төлек бәяләре 30 процентка күтәреләчәк.

Шәһәр урамнарында татарча игълан, элмә такта, реклама язулары күренми икән, димәк, сез Казан шәһәрендә.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

ҺАМАН ШУЛ УК ХОККЕЙ

Михаил ЛАРИЧЕВ (Пушкин)



Василий АЛЕКСАНДРОВ (Санкт-Петербург)



Александр ПАШКОВ (Мәскәү)



Абау!

БЕР СЕРГӘ КИМРӘК

Казан егете Илдар Шәйдуллин бөтен Россия күләмендә сенсация ясады. Ул гади сатып алучыларны «промышленный шпионаж»-да гаепләнү куркынычыннан азат итте. Берзаман аны «Кольцо» сәүдә үзәгенең интерьерын фотога төшергәндә тоткарлыйлар. Кибетнең иминлек саклау хезмәткәрләре һәм директор фотоларны юкка чыгаруны таләп итәләр, имеш, аларда «коммерция сере» булуы мөмкин. Илдар фотога төшерүне тыя торган законны күрсәтүләрен сорый, ләкин ул беркемнән дә анык җавап алу бәхетенә ирешә алмый. Аның каравы, һәвәскәр фотографка прокуратурадан супермаркет хезмәткәрләренең гамәлләре законсыз булуы турында ачык җавап килә. «Секретный» кибетнең директоры дисциплинар җаваплылыкка тартыла, ә уяу сакчылар белән әңгәмә үткәрелә.

КҮҢЕЛ АЧУНЫҢ КҮҢЕЛСЕЗ АХЫРЫ

Күптән түгел Кисловодскидагы «Снежный барс» ресторанында ял итүче берничә дистә кешене җирле эчке эшләр бүлеге начальнигы полковник Игорь Артюхов күрсәтмәсе буенча полиция бүлекчәсенә китерелде. Алар полиция начальнигы һәм аның Чечнядан килгән дусларына «күңел ачарга» комачаулаганнар икән. «Чистарту» операциясен уңышлы тәмамлагач, кызмача полицейскийлар үз уеннарын дәвам итәләр: хәмер эчәләр, стриптизер кызларның аулак җирләренә акча кыстыралар. Залдан алып кителгән кешеләр арасында очраклы рәвештә прокуратура хезмәткәрләре дә булып чыга. Алар погонлы «хуҗа» өстеннән Россия эчке эшләр министрына шикаять язалар. Күңел ачарга яратучы полковникның киләчәк язмышы хәзер үзәктән киләчәк тикшерүчеләр кулында.

ГАИЛӘ ЭЧЕНДӘГЕ БУРЫЧЛАР

Италиядә гаилә эчендәге интим мөнәсәбәтләрне тәртипкә кертү турында закон әзерләнә. Закон ир белән хатыннан даими рәвештә җенси мөнәсәбәтләргә кереп торуны таләп итә. Әгәр дә ике якның берсе ниндидер сәбәп буенча бу таләпне үти алмаса, ул аңлатма язарга тиеш, һәм бу «үтәмәү очрагы» бурыч булып санала. «Бурыч» вакытында кайтарылмаса, кимсетелгән як полициягә мөрәҗәгать итә ала. Ә полиция, үз чиратында, «бурычлы як»ны штрафка яисә җәмгыять эшләренә тарта. Шулай итеп, хакимият итальяннарның интим тормыш белән бәйле күпсанлы шикаятьләреннән арынмакчы була. Илдә ел саен бу мәсьәләгә кагылышлы биш мең чамасы эш карала икән.

ТОРАК МӘСЬӘЛӘСЕ

Коммуналь түләүләр белән проблемалар болай да күп. Ә илдә хәзер яңа бәла. Торак хуҗалары үзләренең мәйданнарында йөзләгән мигрантларның теркәлгәннәрен, штраф квитанциясе килгәч кенә беләләр. Бер квадрат метрга туры килгән якын-тирә илләрдән чыгучылар саны, акылга сыймаслык. Ләкин миграция хезмәте берни дә эшли алмаганын белдерә. Чөнки теркәү почта аша эшләнә, хуҗаның ризалыгы кирәкми. Ә сезгә, мисал өчен, Кыргызстаннан ничә кеше кунакка килүе — сезнең шәхси эшегез. Моңа да карамастан, "кунак итүчене" миграцион кагыйдәләрне бозган өчен зур суммага штрафка тартырга мөмкин. Миграция хезмәткәрләре документларга күз-колак булырга кушалар. Гаепсез кеше гаепле булып кала торган нинди закон соң бу?

Социаль ипотека турында сүз дә кузгатып торасы да юк. Яшь гаилә, кечкенә бала белән ипотека буенча торак ала алмый, чөнки әти-әни йортында артык квадрат метрлары бар. Социаль дип аталуы да матур сүз генә, түли-түли ыштансыз калуың мөмкин. Процентлары "доступное жилье" аңлатмасыннан бик еракта тора.



Валерий ТАРАСЕНКО (Мурманск)

ӘЙБӘТ СҮЗЛӘР

Хатыным эштән бер дә булмаганча күтәренке кәеф белән кайтып керде. Күзләре янып тора, ә кулында торт белән бер шешә шәраб. Мондый хәлдә мин аны соңгы тапкыр егерме еллар элек, үзебезнең туебызда күргән идем.

Башымнан шик йөгереп узды. Нужәли, мәйтәм, берәр яшь егет белән чуала башлаган инде бу?

— Нәрсә булды? — дип сорыйм үзем сак кына. — Шатланырлык нәрсә булды? Зарплатаңны арттырдылармы әллә?

— Арттырдылар, ди, сиңа!

— Ызначит, яңа тун алгансың!

— Нәрсә, акча биргәнең бармы әллә?

— Алай булгач, эш нәрсәдә соң? — дим мин, сабырлыгым җуеп. — Сөйлә бөтенесен дә! Алдыйсы булма!!! Мин барысын да беләм!!!!!

— Монда нәрсә сөйлисең инде... — дип елмая хатын. — Эштән соң кибеткә шәраб алырга кердем. Ә сатучы: «Сиңа, сеңлем, 18 яшь бармы соң?» — ди. Мин бераз югалып калдым: «Әлбәттә, бар!» Ул һаман шикләнә: «Паспортыңны күрсәт!» — ди. Күрсәттем. Шулхәтле рәхәт булып китте! Мондый сүзләрне күптән ишеткәнем юк иде.

— Ә шәрабны нәрсәгә алдың?

— Эх син! — диде хатыным моңсуланып. — Бүген бит өйләнешкәнебезгә егерме ел тулды...

Раф ИБРАҺИМОВ

КАЗАН



Александр КОСМЫЛИН



- **Ипотека — ул дәүләт биргән җәза түгел, шуңа күрә амнистия көтеп булмый.**

- **Ришвәтче эләктергән бер төргәк акча законнан өстенрәк булып чыга.**

- **Шәһәрнең теләсә кайсы районына күченеп яши башла, анда сине барыбер перфораторлы күршең эзләп табачак.**

Мөҗип ШАКИРОВ

ЛЕНИНОГОРСК

Илдар НӘФИЕВ



Илдус АЗИМОВ



Виталий ФЕОКТИСТОВ



Ышансаң — ышан...

ҖИТӘРЛЕК ТҮГЕЛ...

Җәй. Тәрәзәләр ачык. Балконга тартырга чыктым. Астагы тәрәзәдән тонык кына трибуналар гүләве, комментаторның дулкынланган тавышы ишетелә. Күршедәге балконнан бер баш тырпаеп чыга һәм:

— Эй Петрович! — дип кычкыра.

Трибуналар шаулаган тәрәзәдән аңа күршесе тавыш сала:

— Нәрсә?

— Тавышын арттыр әле, минем телевизорның тавышы бетте.

— Алай булгач, миңа кер!

Җавап булып гади һәм шул ук вакытта даһи диярлек җөмлә яңгырый:

— Ю-ук, минем сыра сиңа житәрлек түгел!

М. АНТОНОВ

МӘСКӘҮ

КЕЧЕ КОМАНДИР

Фатирымда ишек алыштырырга булдым. Заказ бирдем. Ишекне куярга ике таҗик килеп, эшкә керештеләр. Эш «перекур»сыз, тиз барды. Аларны күзәтеп, яшьрәгенең өлкәне белән җитәкчелек иткәнен, вакыт-вакыт аңа җикергәләп алганын да абайладым.

Эшчеләрем чәй эчәргә утыргач, үзләре турында сораштыргалап алдым. Алар бертуганнар икән.

— Нигә соң син абыең белән җитәкчелек итәсең? — дип сорадым мин кечесеннән. — Бу бит сезнеңчә түгел...

— Ә мин Россиягә аннан алдарак килдем! — дип җавап бирде горурлык белән «кече командир».

А. ГАЙСИНА

КАЗАН

ВӘТ ЯШЬЛӘР!

Автобуста барам. Минем алда ике әби «яшьләр тегеләй, яшьләр болай» темасына сүз куертып баралар. Имеш, алар тәрбиясез дә, ялкау да, эчәләр, тарталар да. Һәм иң мөһиме — акча яраталар...

Тукталышта салонга бер егет килеп керде. Кондукторга акча бирде дә бер сум сдача алды. Ләкин тәңкә кулыннан ычкынып, әбиләрнең утыргычы астына тәгәрәп керде. Егетнең аны күтәрәм дип иелүе булды — кинәт арткы яктан чалбары ертылды да китте.

— Менә, әйтәм бит, — диде әбекәйләрнен берсе. — Бер сум өчен арт ягын ертырга әзер бит алар!

Бөтен автобус тәгәрәп көлде. Егет, уңайсызланып, беренче тукталышта ук төшеп калды. Әбиләр исә, үз хаклыкларына өстәмә дәлил алганнарына бик риза булып, юлларын дәвам итте.

А. ЖУРАВЛЕВ

ТҮБӘН КАМА

Рашат НИЗАМИ

КРИЗИС ТУРЫНДА

Бу кризис дигән нәрсәкәйдән
Булмас, ахры, мәңге котылып:
Ишекләрдән куып чыгарасың,
Ә ул әнә
Моржадан ук керә котырып.

БАТЫП ҮЛДЕ...

СССРда аракыга каршы
Көрәш ачкан идек берзаман.
Әмма эчүчелек диңгезендә
Батып үлде янә, фаразан.


КАЧКЫН

Әҗәткә дип бер мең тәңкә акча
Биреп торган идем баҗага...
Айлар буе миннән качып йөри,
Гүя, ерактагы аҗаган.

Эрнест ДЫШАЕВ



Виктор ФЕДОРОВ



Ринат АБЗАЛОВ



Фәнзаман БАТТАЛ

ГАРМУНЧЫ ГАПТЕРИ

Яңа фатир алгач, таныш-белешләремнән гел бер хәбәр ишетәм.

— Гармунчы Гаптери күршесенә эләккәнсең икән, — диләр.

— Теге гармунчы Гаптери торган йорттан алгансың алайса фатирны, — дип сүз кыстыручылар да бар.

Тегендә барсам да — "Гармунчы Гаптери", болай борылсам да — "Гармунчы Гаптери". Үзем эчтән генә куанып йөрим. Әһә, мәйтәм, шәп күршегә тап булганмын икән, дим. Гармун чыңнары стена аркылы колагыңа кергәләсә дә ни тора!

Әйберләрне күчереп, урнаштырып бетердем дә фатирны "юдырып" алу хәстәрен күрергә керештем. Төрледән-төрле хәмер сатып алдым, хатыннан мул гына өстәл әзерләттем.

Чакырылган кунаклар исемлегендә күршем Гаптери дә бар иде дисәм, беркем дә гаҗәпләнмәс. Беренчедән, күрше — бергә сайрашып яшисе кеше; икенчедән, әлеге дә баягы, гармунчы. Мәҗлестә берничә көй тартып җибәрсә дә, өстәлләрең түгәрәкләнеп китәчәк бит! Дөрес, аны чакырганда гармун турында бер сүз дә кузгатмадым. Ник дисәң, "гармун уйнау өчен генә кирәк булганмын икән" дию бар. Шулай да ул утырачак урынның сул ягында гармун тартырлык урын калдырдым. Улым өйрәнмәсме дип, узган ел ук алып куйган "Шуйский" хромканы Гаптеринең буе җитәрлек урынга куйдым. Музыкаль йөрәкле кеше түзмәс, үзе алып уйнар, әлбәттә. Түбәтәй астына бер-ике йөз граммны да кыстырып куйса, уйнамый кая барсын!

Хуш, мәҗлесне башлап җибәрдек шулай, берәр рюмканы кәгеп тә куйдык. Үзем кунакларны кыстыйм, шул ук вакытта астан гына Гаптерине күзәтәм. Ниһаять, карап-карап торды да минем хромканы кулына алды, каешларын капшап-капшап үтте, күрек аралыкларын игътибар белән карарга тотынды... Әһә, дим эчтән генә, сыздыра бу хәзер! Ләкин күршем гармунны урынына кире шудырды. Ошамады моңа гармун, мәйтәм, уйнарга да теләмәде. Шулай да күңелдән җылылык китмәде. Бераз утырыр да үзенекен алып керер дип өметләндем. Күршем исә кабактай йөзендәге кылычтай борынын сарган тир бөртекләрен җиңе белән сөртә-сөртә эчүен, ашавын белде. Мәҗлес мәҗлес белән инде ул, сикрит-микрит түгел, үземнең дә башка китеп өлгергән иде. Түзмәдем:

— Бер-ике көй тартып җибәр әле, күрше, — дидем.

Гаптери ишетмәмешкә салышты. Тагын бераз эчеп-ашап утырды да капыл гына урыныннан купты.

— Гаеп итмәгез, җәмәгать, ашыгам, хатынны эштән каршылыйсы бар, — дип чыгып та шылды.

Ул арада икенче күршем киң итеп елмаеп җибәрде:

— Гаптеридән гармун уйнатмак булдың алайса. Көйне көйдән дә аера белми бит ул.

— Ничек инде?

— Гармун белән алыш-биреш итеп яшәгән кеше ул. Берәүләрдән ала тора, икенчеләренә кыйбат хак белән сата тора. "Гармунчы" кушаматы да шуннан гына килә.

Николай **ВОРОНЦОВ** (Санкт-Петербург)



ҖӨМЛӘ

● Кичә тәрәзәләрне юганнан соң, таң ярты сәгатькә иртәрәк ата башлады.

● Бәйрәм алдыннан аптекаларда сөеклеләренә бүләк алучы пенсионерлар шыгрым тулы була.

● Яз. Кызларда беренче кендекләр бүртеп чыкты.

● Бүген, ниһаять, үземне ир кеше итеп күрсәттем. Чүп чиләген чыгардым.

● Ни дисәң дә, Дарвин тәгълиматы дөрес бугай. Зоопаркта күпләр маймыл читлеге янынннан чырайларын бозмыйча уза алмый.

Кирилл БЕРЕНДЕЕВ

МӘСКӘҮ



Илгизәр **ФАЗЛУЛЛИН**

Мөхәтдингә тап булсаң...

Мөхетдин дә, Хәмит тә минем якын танышларым. Алар икесе дә Идел аръягындагы бер авылда көн күрәләр. Җәй көннәрендә мин үзем дә бу авылга кайткалап йөрим. Хәмитнең төртмә телле булуын, нәрсә турында гына сөйләсә дә арттырып җибәргә һәм үзен күрсәтү өчен мактанырга да күп сорап тормаганлыгын авылдашлары яхшы белә...

Мөхетдиннең дә бөтен авылга билгеле булган шаян бер шөгыле бар. Ул — кытыкчы. Кәрәктәй кулларын сузып күрешүе була, шунда ук ул кеткелдәп көлеп һәм үз итеп, сине кытыклап алырга да күп сорамый. Аның минем үземне дә кычкыртып кытыклаганы бар. Янә тап була күрмәсәм иде үзенә дигәндәй, әле дә булса шүрләп йөрим.

Шулай, бер көнне мин авылга кайтып төшкәч, кибет янындагы яшел үләндә "мужик"ларның гәпләшеп торуларын күреп алдым. Араларында җиңелчә генә тамак "чылатканнары" бар. Һәркайсы да авызларына су капканнар диярсең, Хәмитне тыңлыйлар. Сандугачтай сайрый гына бит Хәмит: "Менә әле кичә генә явыз үгезне чүт кенә егып ташламадым бит, егетләр. Ферма янынннан узып барганда күзләрен акайтып миңа карап тора. Аннан, пырхылдый-пырхылдый, миңа табан килә башлады. Сөзәм дип кенә торганда, ике мөгезеннән эләктереп алдым да, уңга-сулга селтәнеп, аны егарга гына торганда, теге явыз мине чөеп җибәрмәсенме! Сыртыма барып төшкәнемне үзем дә сизми калдым. Аякларыма бастым да, "явыз"ның тагын мөгезләренә ябыштым. Ярый әле, минем белән тагын мәшәкатьләнеп торасы итмәде, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, горур гына атлап, яшь тана ягына китеп барды..."

Аны тыңлаучылар: "Ну батыр да соң инде үзең!" — дип Хәмитне куәтләп кенә тордылар. Ә ул һаман да сүзен дәвам иттерде: "Батыр, кәнишне. Мин авылыбызның иң явыз этеннән дә курыкмыйм, ыржаеп якын килүе була, койрыгыннан гына борып алам".

Шул чагында минем янәшәмдә генә басып торган Мөхетдин, башкалар ишетмәслек кенә итеп, уң колагыма пышылдады: мактанчык тәре, кара инде, үзе кандала кебек кенә, ни буе, ни ите юк..."

Хәмит тагын ниләр генә сөйләгән булыр иде, Мөхетдин шыпырт кына аның артына басып, җәһәт кенә аны ике култыгы астыннан кытыкларга кереште. Бугаз киереп, борчак сипкән Хәмит, ах-вах килеп шаркылдап көлә һәм "җибәрә күр" дип кычкыра-ялвара, камырдан әвәләнгән кеше кебек, бөгелеп кенә төште.

Икенче бер кайтуымда безне дуслар мәҗлескә чакырды. Ни күрим, Мөхетдин дә, Хәмит тә монда. Хәер, нибарысы 15-20 ир-аттан гына торган авылда бер-берсен белмәгән, бер-бере белән йөрешмәгән кеше юк та бит ул.

Әлеге дә баягы, Хәмит монда да үзен өскә куеп, бер авылдашын "чәйнәп" маташа. Ул шундый да... шундый, имеш. Аның биредә булмавыннан файдаланып булса кирәк, галәмәт арттырып та җибәрә. Башкалар, нишләсеннәр, тып-тын калып аны тыңлыйлар. Күрәм, тик Мөхетдин генә тыныч түгел. Менә ул түземлеге бетеп, урыныннан сикереп торды да: "Әллә кытыгың киләме?" — дип сорап куйды. Бу сүзләрне ишетеп Хәмит, шып булып, урынына утырды.

Үткәннәргә карыйк кайрылып...

МИРСӘЙ ӘМИРНЕҢ ТУУЫНА — 105 ЕЛ

НКВД ТӘМУГЫННАН

Мирсәй Әмир — әдәбият хакына, "Чаян" хакына НКВД тәмугларына төшкән кеше.

Көннәрдән бер көн камера ишеге ачылып китә һәм Мирсәй Әмиргә :

— Амиров, с вещами на выход! — дип кычкыралар.

Әштер-өштер җыенып, ишеккә таба атлый Мирсәй Әмир.

— Бөтен буыннарым, барлык әгъзаларым тораташ каткан килеш ишектән чыктым. Чыксам — өеңә кайт, диләр.

Шулай исән калган Мирсәй Әмир гомере буе юмор, әдәбият яратучыларны иҗаты белән сөендерде.

Олы юбилее көнне безгә кыска гына гыйбарә әйтте:

— Төрмәдә утырмаган язучы тормышны белми инде ул, егетләр, — диде.

Мирсәй Әмирнең бөек башын кече итеп редакцияләргә килгән чакларын, салмак әңгәмә корган көннәрен әле дә сагынып һәм яратып искә алам. Тапкыр да, җор да иде Мирсәй ага.

Рәшит ЗӘКИЕВ

ФАҖИГАЛЕ МӘХӘББӘТ

(Чеховтан бозыбрак алынды)

Мин аның белән кайчан танышканмындыр, анысын белмим. Тик мин аңардан бер генә секундка да аерыла алмыйм һәм аның сүзеннән чыкмыйм. Аңар шулкадәр нык бирелгәнмен, шулкадәр нык буйсынганмын, үз гомеремдә аның сүзе буенча йөрмәгән бер генә көнем барлыгын да хәтерли алмыйм. Ул үзе дә мине бер генә секундка да ялгызымны калдырмый, һәрвакыт минем янымда. Мин дә аңардан аерылып торырга тырышмыйм. Димәк, безнең арада якынлык бик көчле! Ләкин, хөрмәтле кызлар һәм хөрмәтле яшь киленнәр! Безнең бәхетле тормышыбыздан көнләшмәгез. Безнең бу фаҗигале якынлыгыбыз минем өчен бертөрле дә файда бирми. Киресенчә, бу якынлык миңа зарар китерә. Беренчедән, ул, минем иптәшем, бер генә секундка да минем янымнан китмәве белән миңа эшләргә уңайсызлый. Аның аркасында халыктан сүз ишетәм. Аның хакын саклап, кеше күзе алдында дәрәҗәм төшә. Ләкин ул назлы бикә аларның берсен дә аңлый алмый, аңларга да теләми. Менә әле дә, мин шушыларны язып утырам, ул минем яныма килгән дә, кулымны тота, башымны сыйпый, күзләремнән үбә.

— Җитәр инде, җаным, әйдә ятыйк, тәмле итеп йоклыйк, — ди, мине түшәккә өстери. Мин аңар буйсынам, артык яза алмыйм. Ул миңа сөлек шикелле ябышкан да каләмне ташларга куша. Һаман түшәккә тарта. Каләмемне кулымнан төшермәс борын сезгә аның исемен язып калыйм, аның исеме дә башкаларныкына охшамаган, ямьсез исем. Аның исеме — Ялкаулык.

Мирсәй ӘМИР

Илгизәр ФАЗЛУЛЛИН

БОЗ һәм БЕЗ

Яңгырдан соң нык суытты,
Юллар шәрә боз.
Минем алда "гөрселдәде"
Егет белән кыз.

Юк, белеп бетермиләр шул
Яшьләр барысын да;
Бәла бит ул читтә йөрми,
Аяк астында.


Аяк астында — шәрә боз,
Шугалакмыни.
Нигә берсе бер сүз әйтсен
Сүгенми-ними.

Узган елда да шундый хәл
Булды, югыйсә;
Түздек бит, кышлар да узды,
Һәм без дә исән.

Бәла — аяк астында, дип,
Кабат әйтәмен;
У-у-ф-ф! —
мин дә барып төштем,
Мин дә мәтәлдем.

ЧАЯННЫҢ АЛТЫН САНДЫГЫННАН

Лия БОЧКОВА **(Чаян № 2, 1980)**



— Бу курчак түгел — минем кызым! Балалар бакчасына урнаштыра алмыйм...

Юрий ДЕНИСОВ **(Чаян № 4, 1980)**



— Шушы инструментларны һаман списайт итеп булмый...



* * *

География дәресендә.

— Картада Апеннин ярымутравы формасы белән нәрсәгә охшаган?

— Резин итеккә.

— Дөрес, ә ни өчен резин?

— Чөнки Италия бөтен яктан су эчендә.

* * *

— Син кайчан «икеле» ташудан туктарсың инде? — ди әтисе улына.

— Каникулларда, әти...

Заһир ХӘКИМОВ



— Борчылма, балакаем! Бу даруны миңа вируслардан саклый дип врач язып бирде!

ХӘЛЛӘРЕМ КАЛМАДЫ...

Физкультура сөймәгән укучы монологы

("Суда, суда" көенә җырлана)

Отжимание дисәләр,
Чәчләрем үрә тора.
Иң яратмаган дәресем —
Ыспорт һәм физкультура.

Куш.: *Суда, суда,*
Суда йөзәләсеңме?
Илле отжиманиедән
Үлми түзәләсеңме?

"Гусыйный шаг" дигәннәрен
Кемнәр уйлап чыгарган?
Издевательство бу
Арык укучылардан.

Куш.: *Суда, суда,*
Суда йөзәләсеңме?
Ата казларга охшатып
Йөгерә беләсеңме?

Чаңгыларны җенем сөйми,
Сындырып атар идем.
Чаңгы юлына аркылы
Сузылып ятар идем.

Куш.: *Суда, суда,*
Суда йөзәләсеңме?
Бу хәлләргә мин түзәлмим,
Ә син түзәләсеңме?

Түзәр хәлләрем калмады,
Зинһар ярдәм итегез.
Физкультура дәресеннән
Освобождать итегез!

Куш.: *Суда, суда,*
Суда йөзәләсеңме?
Бу хәлләргә мин түзәлмим,
Ә син түзәләсеңме?

Гүзәл АИТОВА

АЗНАКАЙ районы,
ӘСӘЙ авылы.

* * *

Имтихан. Укытучы «бишле» алырга теләүчеләр өчен сорау бирә:

— Минем исем-фамилиям ничек?

Тынлык.

— «Дүртле» алырга теләүчеләр өчен сорау: бүген нәрсә буенча имтихан бирәсез?

Чебен очкан тавыш та юк.

«Өчле» алырга теләүчеләргә:


— Дәреслек нинди төстә?

Арттагы рәттә берсе икенчесенә пышылдый:

— Тәки батыра бит бу безне...

Владимир МИЛЕЙКО (Санкт-Петербург)





КУНАКЧЫЛЛЫКМЫ СОҢ БУ?

Ровеньки бистәсе юлында милли киемнәрдән ир һәм хатын-кыз сыннары тора. Җиңел арба янында торган ир кешенең кулында гармун, ә хатын-кызныкында — сөлге белән ипи-тоз. Бу сынлы ансамбль читән белән чикләп алынган. Аңлашылганча, бу күренеш минем якташларымның кунакчыл һәм ачык йөзле халык икәнлеген дәлилләргә тиеш. Ләкин бу сынлы ансамбльне урнаштырганда, бу хакта онытып җибәргәннәр, күрәсең. Аны нишләптер юл читендәге чокырга урнаштырганнар. Ул сынны тулысынча күрер өчен абына-сөртенә төшеп, якын үк килеп карарга кирәк. Чөнки юлдан караганда хатын-кыз сурәте ипи-тозны капка яныннан түгел, ә читән аша тәкъдим итә.

Мин бу эшкә кагылышлы администрация түрәсенә соравымны бирәм:

— Әйтегез әле, Ровеньки бистәсендә ипи-тозны читән аша тәкъдим итмиләр иде, нишләп мондый әкәмәт килеп чыкты икән?

— Болар бит тәкъдим итеп тормыйлар, ә бары күр-сә-тә-лә-әр! — дигән җавап ишеттем.

Ю. МАКАРОВ

РОВЕНЬКИ бистәсе,
БЕЛГОРОД өлкәсе.

ЫШАНУДАН АРЫГАЧ

Хөрмәтле Чаян! Гадәтләнгәнбез инде, коммуналь хезмәтләр өчен счет-фактура алдык исә, барабыз да түлибез. Идарә итүче компания анда нәрсә "сырлагандыр" — артык кызыксынып тормыйбыз, ышанабыз.

Ә менә Чаллының ГЭС бистәсенең 5-9 нчы йортларында яшәүчеләр үзләрен "элеккегечә" тотмаска булдылар, күмәк җыелышта "Жилкомсервис" идарә итү компаниясенең шикле исәп-хисап кәгазьләрен капиталь һәм агымдагы төзәтү эшләре өчен түләмәскә карар кылдылар. Бу әмәкәт коммуналь хезмәткәрләре сарыф ителгән чыганакка смета һәм хезмәт өчен түләнү графигын биргәнче барачак. Ут һәм су өчен фатирда яшәүчеләрнең счетчигы күрсәтмәләре буенча, ул да булса йорт комитеты вәкиле рөхсәте белән подвалдагы счетчикларның тулаем төзек икәнен раслаган очракта гына түләнәчәк.


Кызып киткән халык, хәтта, идарә итүче компанияне узган елда үткәрелгән җыелыш карарын танымаган өчен капиталь төзекләндерү, 2012 ел өчен тарифларны расламаган өчен иск бирергә уйлыйлар.

Артык "кызыксынучылар" белән шикле счет хуҗалары арасындагы ыгы-зыгы нәрсә белән бетәр, вакыт күрсәтер. Әлегә "Жилкомсервис" хезмәткәрләре "баш күтәрүчеләр" белән бергә акт төзеделәр.

Р. ШАМЮНОВ

ЧАЛЛЫ





Виктор ФЕДОРОВ



Виталий ФЕОКТИСТОВ



Мөдәррис МӨХТӘСИПОВ

ЯХШЫ ЯККА ҮЗГӘРЕШ

Рәсәйдә тормыш үзгәрде
Яхшы якка табан:
Элек илне ташлап киткән
Хәерчеләр, ризасызлар.
Ә хәзер канәгать байлар
Ялтырата табан.

БАШКОРТОСТАН

ҖӨМЛӘ

● Бөтен балачагын "сугыш уены" уйнап үткәргән малай, үсеп егет булгач, хәрби комиссариат белән "качышлы" уйный башлады.

● Бу дөньяда кешегә һәрвакыт кеше булып калырга кеше булмаган кешеләр комачаулый.

● «Әрсезлек — ярты ризыкка, дигән, ди, супермаркетка ярты ставкага урнаша алган бер үткән хатын.

Марс АХУНОВ

КАЗАН



Илдар НӘФИЕВ

ТӘҖРИБӘ ӨЙРӘНҮ

Журналист итальян делегациясеннән интервью ала:

— Сез безнең якларга нинди максат белән килеп чыктыгыз?

— Менә, сезнең авыл хуҗалыгы тәҗрибәсен өйрәнәбез.

— Авыл хуҗалыгының?!!

— Әйе! Безгә эшне болай оештыру турында әлегә хыялланырга гына туры килә. Сезнең агрофирмаларыгыз — бу бит фантастика! Дәүләтегез аларга ел саен дотация, льготалы кредитлар биреп тора, бурычларын үз өстенә ала. Крестьяннар үз җирләрендә бушлай диярлек бил бөгә. Бу бит ышанмаслык! Агробароннар аларның продукциясен тиеннәргә сатып алып, дистәләгән сумнарга сата! Бу — искиткеч! Ә саткач: «Үзебезгә зыянга эшлибез!» — дип шәрран яра. Ә чиновниклар ул «зыян»ны каплап бара. Бу бит безнең төшкә дә керми!

— Сез фермерлармы?

— Сез нәрсә! Без — мафия!

● ● ●

Бер малай, балык консервасы тотып, урам чатындагы полицейский янына килә:

— Абый, ачып бирегезче шушыны.

Полицейский таягы белән банкага шакый:

— Ачыгыз, полиция!

● ● ●

Судья:

— Бу бит дөнья күрмәгән оятсызлык! Башта затлы тун урлагансыз, ул гына аз тоелган — акча да әләктереп киткәнсез.

Гаепләнүче:

— Аңлагыз мине, судья әфәнде, шундый кыйммәтле тун кигән килеш ничек акчасыз йөрмәк кирәк?!



Ринат АБЗАЛОВ

ЧуАр пресса

ВӨҖДАНЫ ӘЙТКӘН

Узган гасырның кырыгынчы еллар ахырында Сиэтл шәһәрендә яшәүче бер ир кибет кассасыннан 30 доллар акча чәлдергән булган. Күптән түгел ул бу акчаны процентлары белән әлеге кибеткә кайтарып биргән. Язып калдырган запискасында үзенең гөнаһлы эш эшләвен таныган һәм конверт эченә 100 доллар акча да салган.

Магазинның менеджеры әйтүенчә, бу олы яшьтәге кешенең, күрәсең, вөҗданы кузгалган һәм үзенең хатасын төзәтергә карар кылган. Сатып алучылар картның бу гамәлен бик хуплаган, ә акчасын мохтаҗ кешеләргә бүлеп бирәчәкләр икән.

КАБАРТМА ИРЕННӘР

Мультфильмдагы яраткан героинясы Джессик Рэббитка охшарга тырышып, Санкт-Петербургта яшәүче Кристина Рэй битенә йөз силикон инъекциясе ясаткан. Бу аңа 195 мең сумга төшкән.

Кызый балачагында ук үзенең иреннәре нечкә булуына эче пошкан. 17 яше тулгач, ул беренче тапкыр матурлык салонына бара һәм беренче уколны ала. Шуннан соң косметологлар янына даими йөри башлый. Хәзер ул берничә айга бер укол ясата һәм киләчәктә дә шулай дәвам итмәкче икән.

Өреп тутырылган кабартма сыман иреннәрен көзгедә күреп, Кристина елмая һәм шатлана.

БИК КҮРКӘЛӘНЕП ЙӨРСӘҢ...

Бу вакыйга АКШның Питтсбург каласында, җирле халыкның күркә ите белән сыйлана торган игелек кылу көнендә була. Кайдандыр очып килгән бер кыргый күркә ресторан тәрәзәсенә килеп бәрелә. Витрина пыяласы чыдамый, ватыла, ә күркә ресторан залы идәненә килеп төшә. Бу вакытта әле залда бер җан иясе дә булмый, шуңа күрә кешеләргә кыю кошның зыяны тими. Киресенчә, ресторанга ашарга йөрүчеләр аннан файда күрә. Казанда күркә ите пешә һәм табынга куела.

КҮҢЕЛЛЕ КУНАКЛАР

Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр


Мирослав ФЕТНЕР



Мирослав КЕМЕЛ



Вацлав ЛИНЕК



АКЧА ХУҖАСЫН ТАНЫМЫЙ

Сәфәрхуҗа товарларын беркайчан да акчага сатмый. Акчага мохтаҗ халыкка бик уңай бу. Берсе, кызыксынып, сорап куя:

— Абзый, синең акчаң бик күп, ахры, шуңа күрә алышбиреш итеп кенә йөрисең?

Тегесе аптырап калмый:

— Акча үзе картаймый, ә бик күпләрне картайта, кешеләрне аера һәм дошманлаштыра, бер-берсенә ят итә, дустым. Кайчандыр, акыллы бер зат әйткән ди: "Акча — бик тә яман хуҗа, әмма гаять уңган хезмәтче". Минем холкыма туры килә аның мәгънәле сүзләре. Шуңа күрә акчалы бай да, хәерче хезмәтче дә булырга теләмим. Минемчә, акчасы күп кеше түгел, бәлки булганын тота белеп, җитә дип яшәгән адәм бай...



Мәгъсүм ГӘРӘЕВ. Эрот ЗАРИПОВ портреты.

Сәфәрхуҗа тартмаларында акча турында кырыкмаса-кырык кызык хикәятләр бар. Шуларны сөйли дә, сатып алучыларына: "Акча колы булып комсызланып йөрер хәлем юк", — дия икән.

МОНДА ДА БЕР ТИЕН

Хәммәди, зимагур булып, табылмаган бәхетен читтән эзләп, акча сугарга чыгып киткән, ди. Илдән илгә каңгырап йөреп, эше уңмагач, бөтен дөньясына төкерә дә бер тиенсез өенә кайта. Тәмләп чәй эчәргә утыра. Әнисе, эше барып чыккандыр, ахры, моның дип, шатланып:

— Йә улым, ничек соң акча төшерә алдыңмы? — ди.

— Юк, әни, бер тиен дә алып кайтмадым.

— Нишләп алай?

— Читтәге бер тиен монда да бер тиен генә тора икән. Шулай булгач, аны нишләп алып кайтып йөрим, ди.

КЕШЕ КӨЙМӘСЕН ИШМӘ!

Казан олигархы Иделдә ишкәкле көймә белән йөрергә чыккан, имеш. Кайтыр вакыт якынлашып килә. Тегенең көймәсе яр буйлап үз җаена гына йөзгәндә, бер малай, аркан ташлап, көймәне тарта башлаган. Хәйдәр бай шиккә калган:

— Әй малай, нигә азап чигәсең? Көймәдә урын күп, кил, утыр, икәүләп ишәрбез.

— Юк, олигарх абый, әти миңа: "Эт сөйрә дә акча тап, әмма кеше көймәсен ишмә!" — дип васыять әйтеп калдырган иде. Сөйрим әле, бәлки акча җәлләмәссең!..

ТАУ КУРКА

— Бер дә дөрес түгел инде бу. Тау аннан нигә курыксын да, куркып нишләсен? — дигәннәр үсмерләр.

Моңа каршы бер карт:

— Менә ничек ул, оланнар. Бай кеше үзенә кирәк тапса, акчасына кешеләр яллый да тауны казып икенче җиргә күчереп өяргә куша. Шуңа күрә тау курка, — дип җавап биргән.

ТИМӘ МИҢА!

Яңа заман полицейские пост будкасында, эш юклыктан аптырап, чебен үтереп утыра икән. Кинәт чебеннәрнең берсе телгә килә:

— Тимә миңа! Өч йомышыңны үтим.

Полицейскийга кызык булып китә бу һәм теләкләрен әйтә башлый:

— Кеше яшәми торган утрауда буласым килә!

Ни күзләре белән күрсен, ул атауда япа-ялгызы гына.

— Икенчедән, монда үземә генә күңелсез, янымда чибәркәйләр, аракы һәм музыка булсын!

Болары да тормышка аша!

— Тәк, тәк, өченчедән, син мине берни эшләтмичә күп акча алдырып яшәт!..

...Полицейский шул будкасында эшсезлектән эче пошып, һаман чебеннәр үтереп утыруын дәвам итә, имеш.

МИННӘН - ТҮЛӘҮ

Вәгазьче белдерүләр тактасына болай дип язып элә: "Мин һәммәгезгә дә дога кылам!"

Тегене адвокат дәвам итә: "Мин һәркайсыгызны яклыйм".

Табиб өсти: "Мин барчагызны да дәвалыйм".

Гади гражданин башын кашып ала да: "Мин бөтенесе өчен дә түлим", — дип юана.

БОТИНКАНЫҢ КЕСӘСЕ ЮК

Акча алганның икенче көнне хатыны айнып җитмәгән ирен уята:

— Тор, тиз бул, эшкә соңга каласың!

— Син пинжәкне чистарттыңмы?

— Әлбәттә.

— Ботинкаларны?

— Аларның кесәләре юк ич.

Мәгъсүм ГӘРӘЕВ

КАРА ЮМОР



Александр АЛЕШИН



Алексей МАМАЕВ



(СКОРПИОН)

САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 2 (1742) 2012

«Татмедиа» ААҖ филиалы директоры һәм баш редактор
Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: **Ринат АБЗАЛОВ**
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: **Александр АЛЕШИН**
Баш бухгалтер: **Зөлфирә ЗАМАЛДЫНОВА**
Үсеш бүлеге мөдире: **Әдилә БАҺАВЕТДИНОВА**
Җаваплы секретарь: **Минвәгыйз ЗӘЙНЕТДИНОВ**
Бүлек редакторлары: **Петр ШАГРАЙ, Рәшит ЗӘКИЕВ, Марс САБИРОВ, Людмила САФИУЛЛИНА, Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА, Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА**
Офис-менеджер: **Лилия ӘХМӘТОВА**
Дизайнер: **Ләйсән ФӘЛӘХОВА**
Машина йөртүче: **Ринат ГАРИПОВ**

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте.

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль службаның Татарстан Республикасы идарәсендә теркәлде.

Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ТУ 16-00340, 1 апрель 2010 ел.

«Чаян»га Татарстанда, Россиядә һәм БДБда барлык элемтә бүлекчәләрендә һәр айдан язылырга мөмкин.

ТАТАРЧА «ЧАЯН»НЫҢ ИНДЕКСЫ — 73488,
РУСЧАСЫНЫКЫ — «ЧАЯН» («Скорпион») — 73489.
Айга ике тапкыр чыга.

Редакция фикере авторлар фикере белән тәңгәл килергә мөмкин.

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«Чаян»нан икенен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.

Басарга кул куелды 26.01.2012 ел.
Гомуми тираж — 4933
(рус.–2934, тат.–1999)
Заказ М- 3
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Басма табагы 2,1.
Учетн.-изд. табагы 3,1.



Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 562-11-41,
292-39-16,
тел./факс: 292-38-18.



Редакциянең һәм нәширнең адресы:
Декабристлар ур., 2.

Тираж сертификацияләнгән

КЫРЫК ДҮРТНЕҢ ҖӨЕНДӘ...

Түбән очның Сәрвәртдин күршесендә яшәүче Госман дусты белән кабыктан ясалган көймәле, бер кучәрле арбаны тартып, Лашман кыр капкасыннан чыгып баралар. Алар шулай һәр көнне әниләре пешергән умачлы ашларны олы кәстрүлгә салып, ипиләрне киндер ашъяулыкка төреп, басуда эшләүче тракторчы абыйларына һәм апаларына ашарга илтә була.

Юлда малайлар уйнап-көлешеп тә, кызыклы хәлләр турында сөйләшеп тә, хәтта җыр-такмак әйтешеп тә өлгерәләр икән. Шулай бервакыт болар:

Коңгыз баскан түбәгә,
Кычкырадыр: "Каңхуз, каңхуз".
Кәҗә кысылган коймага —
Акыра мескен: "Бетә-ә-ә", "Бетә-ә-ә", —

дип такмаклап көлешәләр.

Артларыннан басып килүче — авылда колхоз оештыручыларның берсе — Шакир абзый Гаффаров теге ләрнең ни такмаклауларын чамалап:

— Кемне хурлыйсыз анда, башыгыз беткерләре! — дип ачуланган, имеш.

Куркуларыннан шүрләгән малайлар:

— Юк, ни, Шакир бабай, без колхоз гына бетә күрмәсен дип җырлыйбыз, — дигәннәр һәм басу юлыннан кызулабрак элдерткәннәр, ди.

"ЭЧТӘРӘ ПАРА, ГЫСАРА..."

Авылыбызның арткы урамында яшәүче Фәсах җизни, Яңа Элмәлегә барып, киез итек басарга заказ биргән. Эшне кыска тоткан Минулла биччә Фәсахны көтә-көтә, кем әйтмешли, саргаеп беткән. Киләсе кунак хөрмәтенә ясаган һәм мунчасына илтеп яшергән бер чирек көмешкәнең дә яртысын үзе эчеп бетерә язган, имеш.

Менә бер буранлы кичтә боларның ишеген берәү шакый.

— Кәсах, синме пу? — дип сорый Минулла карт.

— Әйе, мин бу, Минулла, — дип алдашкан күрше Әмир авылы мужигы Кызыл Исмәгыйль абзый.

Минулла биччә төс-башлары бераз охшаш кунакларны буташтыргανмы, анысы безгә нәмәгълүм. Шулай да ул Исмәгыйль абзыйның тумыштан кып-кызыл йөзеннән танырга тиеш булгандыр дип уйлыйм. Әмма вакыйган аның кунакны Фәсах дип кабул итүе хак.

Өстәл янына утырып яңа итекләрне юалар, исергәнче эчәләр болар. Исмәгыйль абзый киез каталарны да алып китмәкче булган, имеш.

Айныгач, икенче көнне, дөбердәп, Фәсах җизни килеп төшкәч, Минулла биччә болай дип акланган диләр:

— Әй, әй Кәсах, яхшы пулмады пит әле! Сине сыйлыйм тип, мин Әмир алдакчысын сыйлаганмын икән. Әйтәм шул, көмешкәнә эчтәрә пара, гысара бара... Чынаһ кына карасам, ул син түкел, Гысыл Исмай пулып чыкты...

Минвәгыйз ЗӘЙНЕТДИНОВ

ЛАШМАН–ӘМИР–ЯҢА ЭЛМӘЛЕ авыллары
ЧИРМЕШӘН районы.



Ринат АБЗАЛОВ

Таhир ФӘИЗОВ (Татарстан)









— Ә син аның рухын ничек чакырасың?
— Бер стакан салам да китәм...

4 612750 670080